ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Олы Кайбыч ав. № 278

«Торак өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 253 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Ана (гаилә) капиталы чаралары белән эш итүгә бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 мартындагы 35 ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 253 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче кушымтаның 2.5 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гражданның гаилә составынраслый торган документларның (балалар туу турында таныклык (таныклыклар), баланы уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары законлы көченә кергән никахны төзү турында таныклык, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары күчермәләре);»;

4 нче кушымтаның 2.5 пунктындагы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) гражданның гаилә составын раслый торган документларның (балалар туу турында таныклык (таныклык), баланы уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары законлы көченә кергән никахлашу турында таныклык (таныклыклар) күчермәләре, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары);»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров